**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ XXXII СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 137**

Мөслим авылы «20» февраль 2019 ел

**2018 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2019 елга бурычлар турында**

Мөслим муниципаль районы башлыгы Р.Х. Муллинның 2018 елгы социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлар турында хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, Мөслим муниципаль районы Советы, муниципаль берәмлекнең югары вазыйфаи заты вәкаләтләрен башкарганда, район башлыгы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән компетенцияләр һәм вәкаләтләр нигезендә эш итүен билгеләп үтә.

2018 елда муниципаль районның барлык структур бүлекчәләре эшчәнлеге муниципаль районның социаль-икътисадый, инфраструктур үсеше мәсьәләләрен хәл итүгә, социаль өлкә объектлары эшчәнлеген яхшыртуга, торак белән тәэмин итүгә, халыкның хезмәт хакын һәм реаль керемнәрен арттыруга, территорияләрне комплекслы үстерүгә юнәлдерелгән иде. Нәтиҗәдә, 2018 елда район икътисадының күп тармакларында соңгы елларда билгеләнгән тотрыклы үсеш темпларын ныгытуга ирешелде. Район җитәкчелегенең бөтен эшчәнлеге Мөслим муниципаль районында яшәүчеләрнең мәнфәгатьләреннән чыгып, халык тормышының имин шартларын яхшыртуга юнәлтелгән иде.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, район Советының даими комиссияләре фикерен исәпкә алып, шулай ук Мөслим муниципаль районы Уставының район башлыгының район халкы һәм район Советы каршында хисап тотуы турындагы нигезләмәләрен үтәп, Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Мөслим муниципаль районы башлыгының 2018 елда социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2019 елга бурычлар турында хисабын игътибарга алырга.

2. Муниципаль район Советы аппаратының оештыру бүлегенә Совет утырышында, җирлекләрдә халык белән очрашуларда әйтелгән тәнкыйть кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрне гомумиләштерүне, аларны гамәлгә ашыру һәм үтәү буенча чаралар күрү планын эшләүне йөкләргә, аларны үтәү барышы турында даими комиссияләргә хәбәр итәргә.

3. Муниципаль районның башкарма комитетына хисап турында фикер алышканда әйтелгән кимчелекләрне бетерү һәм тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар планын эшләргә һәм бирергә.

4. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә: - Авыл җирлекләре башлыкларына территорияләрне комплексы социаль-икътисадый үстерү буенча эшне көчәйтергә, салым базасын формалаштыру, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлекләр бюджетларына өстәмә финанс чараларын җәлеп итү эшчәнлеген активлаштырырга.

5. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә һәм муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мөслим муниципаль районы Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин